ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**24.05.2022г**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1233**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комиссия турында нигезләмәне раслау турында

Торак хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендәге мәсьәләләрне комплекслы карау, гражданнарның торакка хокукларын саклау мкаксатларында, Россия Федерациясе Торак кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы «Зеленодольскмуниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына, Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комиссия турында нигезләмәне яңа редакциядә, кушымтада каралганча, расларга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 июнендәге 1313 номерлы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комиссия төзү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О. А. Матвеевага йөкләргә

Җитәкче И.Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
24.05.2022 ел №1233

## ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРШЫНДАГЫ ТОРАК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ БУЕНЧА ИҖТИМАГЫЙ КОМИССИЯ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ

### 1. Гомуми нигезләмә

1.1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы торак мәсьәләләре буенча иҗтимагый комиссия (алга таба - – Иҗтимагый комиссия) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы орган булып тора һәм муниципаль милектә булган торак мәйданын дөрес исәпкә алуны, бүлүне тәэмин итү, гражданнар тарафыннан торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру, торактан ирекле рәвештә мәхрүм итүне булдырмау, торак урыннар белән идарә итү, алардан файдалану һәм алар белән эш итү, бозылган торак хокукларын торгызу буенча мөнәсәбәтләрдә катнашучыларның тигезлеген тануфункцияләрен гамәлгә ашыра.

1.2. Иҗтимагый комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе Торак кодексы, Россия Федерациясе норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив-хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Иҗтимагый комиссия Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән төзелә.

### 2. Иҗтимагый комиссиянең составы

2.1. Иҗтимагый комиссия составына комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре һәм әгъзалары керә.

2.2. Иҗтимагый комиссия составында кворум өчен әгъзалар так санда, кимендә 5 кеше булырга тиеш.

2.3. Комиссия утырышлары ике атнага бер тапкырдан да ким үткәрелми һәм Комиссия составының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы санала.

2.4. Иҗтимагый комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә. Беркетмә алып баруны комиссия секретаре башкара, беркетмә алып бару буенча вазыйфасы булмаганда, рәис тәкъдиме буенча комиссиянең теләсә кайсы әгъзасына йөкләнә.

### 3. Иҗтимагый комиссиянең эшчәнлеген оештыру

3.1. Иҗтимагый комиссия рәисе комиссияне җитәкли һәм аның эшен оештыра. Иҗтимагый комиссия рәисе булмаганда, җитәкчелекне аның урынбасары башкара.

3.2. Комиссия Секретаре:

3.2.1. Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә материалларны карауны тикшерүне һәм оештыруны гамәлгә ашыра;

3.2.2. Иҗтимагый комиссия утырышында каралырга тиешле мәсьәләләрне әзерли;

3.2.3. Иҗтимагый комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

3.2.4. Иҗтимагый комиссия карарлары проектларын әзерли.

3.2.5. Комиссия эшчәнлеге мәсьәләләре буенча барлык документлар Иҗтимагый комиссия секретарендә саклана.

3.3. Комиссия әгъзалары:

3.3.1. Иҗтимагый комиссия утырышларында көн тәртибе мәсьәләләре буенча чыгыш ясыйлар;

3.3.2. Торак комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карар белән килешмәсәләр, Иҗтимагый комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри рәвештә кушылырга тиешле аерым фикерләрен язмача белдерәләр.

3.4. Комиссия карарны ачык тавыш бирү юлы белән Иҗтимагый комиссия әгъзалары арасыннан күпчелек тавыш белән кабул итә. Тавыш биргәндә комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия;

## 4. Иҗтимагый комиссиянең төп бурычлары

4.1. Иҗтимагый комиссиянең төп бурычларыбулып түбәндәгеләр тора:

4.1.1. Аз керемлеләр һәм башка гражданнарның торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә кую турындагы гаризаларын карау.

4.1.2. Россия Федерациясенең гамәлдәге Торак кодексы нигезендә,әлеге мәсьәлә буенча карар кабул итү өчен гаризага кушып бирелгән документларның тулы булуын тикшерү.

4.1.3. Аз керемлеләрне һәм башка гражданнарны найм, социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар дип тану нигезләрен билгеләү.

4.1.4. Гражданнарны Зеленодольск шәһәре һәм Зеленодольск районы территориясендә яшәүче торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу, аларны исәпкә алудан баш тарту, гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптән төшерү турында карарлар чыгару.

4.1.5. Аз керемле һәм торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәптә торучы башка гражданнарга социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирү турында карарлар чыгару.

4.1.6. Коммуналь фатирларда бушаган торак бүлмәләрне бүлү турында карарлар чыгару.

4.1.7. Торак программалары буенча торак шартларын яхшырту өчен кирә торган бюджет акчаларын бүлү турында карарлар чыгару.

4.1.8. Гражданнарны торак программаларына кертү турында карарлар чыгару.

4.1.9. Махсуслаштырылган торак фондыннан, маневрлы фондтан, социаль файдаланудагы торак фондыннан, «Ветеран» МЙ тан торак биналар бирү турында карарлар чыгару.

4.1.10. Гражданнарны торак урыны алу өчен исәпкә алу яисә исәпкә алудан баш тарту турында карар, документларны комиссиягә тапшырганнан соң, егерме биш көннән дә соңга калмыйча, гаризаны карау нәтиҗәләре буенча кабул ителергә тиеш. Исәпкә алу яки баш тарту турында карар кабул ителгәннән соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча, тиешле гариза биргән гражданга мондый карар кабул итүне раслаучы документ җибәрә.

## 5. Иҗтимагый комиссиянең хокуклары

5.1. Иҗтимагый комиссия үз компетенциясе кысаларында түбәндәге хокукларга ия:

5.1.1. Торак мәсьәләләрен карау өчен дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә оешмалардан кирәкле мәгълүматлар, белешмәләр, документлар һәм аңлатмалар соратып алырга һәм алырга;

5.1.2. Комиссия утырышларына вазыйфаи затларны, белгечләрне һәм

гражданнарны торак мәсьәләләрен караганда, алардан кирәкле мәгълүмат һәм аңлатмалар алу өчен чакырырга;

5.1.3. Мөрәҗәгать итүче гражданнарның торак шартларын тикшерү акты төзеп, яшәү урынына барырга;

5.1.4. Торак-эксплуатация оешмаларыннан азат ителә торган торак мәйданы турында мәгълүматны таләп итәргә;

5.1.5. Утырышларда үзенең компетенциясендәге мәсьәләләрне карарга.

## 6. Иҗтимагый комиссия йөкләмәләре

6.1. Иҗтимагый комиссия әгъзалары үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе Торак кодексына һәм башка норматив-хокукый актларга таянып эш итәргә тиеш.

## 7. Иҗтимагый комиссия тарафыннан эшчәнлеген туктату

7.1. Иҗтимагый комиссиянең эшчәнлеге Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә туктатыла.